ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче «Менделеевск шәһәре», «Монашево авыл җирлеге» һәм «Татар Чаллысы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**


«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш), № 3 (I өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш); 2014, № 12 (V өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1нче кушымта

«Менделеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре

**карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 11 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- җирлекнең административ үзәге
- муниципаль районның административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 32 (17) – 12 (18) | - Удмурт Республикасы |
| 12 (18) – 14 (66) | - Әгерҗе муниципаль районы |
| 14 (66) – 25 (64) | - Тукай муниципаль районы |
| 25 (64) – 32 (17) | - Алабуга муниципаль районы |

«Менделеевск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы номеры | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Менделеевск шәһәре |
| 2 | Абалач авыл җирлеге |
| 3 | Бәзәкә авыл җирлеге |
| 4 | Бөрешле авыл җирлеге |
| 5 | Енабердино авыл җирлеге |
| 6 | Ижевка авыл җирлеге |
| 7 | Камай авыл җирлеге |
| 8 | Монашево авыл җирлеге |
| 9 | Монай авыл җирлеге |
| 10 | Песәй авыл җирлеге |
| 11 | Иске Гришкино авыл җирлеге |
| 12 | Татар Чаллысы авыл җирлеге |
| 13 | Тихоново авыл җирлеге |
| 14 | Тойгуҗа авыл җирлеге |
| 15 | Турай авыл җирлеге |

»;

2) 2 нче кушымтаның җиденче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 3 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Бәзәкә, Енабердино, Иске Гришкино, Татар Чаллысы, Монай, Тихоново авыл җирлекләре, Тукай муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.»;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Татар Чаллысы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Татар Чаллысы авыл җирлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Абалач авылыннан 5,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, «Алабуга – Ижевск» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көнбатышка таба 100 м җитештерү объектының төньяк чиге буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 100 м юл буе урман полосасының көньяк чиге буйлап бара, алга таба көньякка таба 200 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 500 м җитештерү объектының көньяк чиге буйлап

бара, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 800 м, көнчыгышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, җитештерү объектының көньяк чиге буйлап көньяк-көнчыгышка таба 400 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м, көнчыгышка таба 5,2 км, «Полянка» станциясенә керү юлларын кисеп үтеп, тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнбатышка таба, 450 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба төньяк-көнчыгышка таба 1,3 км Алабуга – Ижевск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 28 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 27 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

4) 10 нчы кушымтаның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

5) 14 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар Чаллысы авыл җирлеге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Монай, Тихоново авыл җирлекләре, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.»;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып Менделеевск муниципаль районы чиге буйлап Татар Чаллысы авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Тагай авылыннан 3,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 29 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Татар Чаллысы авыл җирлеге, «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Абалач авылыннан 5,0 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 28 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 1,4 км, «Алабуга – Ижевск» – Яңа Менделеевск химия заводы автомобиль юлын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, көнбатышка таба 100 м җитештерү объектының төньяк чиге буйлап, профильле автомобиль юлын кисеп үтеп, 100 м юл буе урман полосасының көньяк чиге буйлап, алга таба көньякка таба 200 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш чиге буйлап, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көнчыгышка таба 500 м җитештерү объектының көньяк чиге буйлап бара,

сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап көньяк-көнчыгышка таба 800 м, көнчыгышка таба 350 м, төньяк-көнчыгышка таба 500 м бара, көньяк-көнчыгышка таба 400 м җитештерү объектының көньяк чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м һәм төньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, көнчыгышка таба 5,2 км, «Полянка» станциясенә керү юлларын кисеп үтеп, тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк чиге буйлап уза, алга таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 550 м көньяк-көнбатышка таба, 450 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 100 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, алга таба 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба Алабуга – Ижевск автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 21 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

г) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татар Чаллысы авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 29 нчы тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап 28 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 18 июнь
№ 49-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында»Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган
**карта-схемасы**







Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Менделеевск муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- җирлекнең административ үзәге
- Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясе составына керүче Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе